МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.06.2026 ел № 272-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Президентының «Гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре вазыйфа биләгәндә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле булган Татарстан Республикасы дәүләт

граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (кушымтада бирелә) (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) расларга.

2. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2014 елның 20 маендагы 188-осн номерлы боерыгын;

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2014 елның 20 маендагы 188-осн номерлы боерыгына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 18 маендагы 392-осн номерлы боерыгын.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман
хуҗалыгы министрлыгының
22.06.2026 ел, № 272-осн
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында вазыйфа биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. «Җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендә дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:
министрның беренче урынбасары;
министр урынбасары;
эшләр идарәчесе;
министр ярдәмчесе;
бүлек башлыгы;
сектор мөдире;
бүлек башлыгы урынбасары.

2. Вазыйфа биләү коррупция куркынычы белән бәйле булган «белгечләр» һәм «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:
әйдәп баручы киңәшче;
әйдәп баручы консультант;
әйдәп баручы белгеч;
1 разрядлы өлкән белгеч.